ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2019 ш.т.б.Алексеевское № 66

**Алексеевск муниципаль районы башлыгының 2018 елның 5 июлендәге 72 номерлы " Алексеевск муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турындагы “ карарына үзгәрешләр кертү турында**

Кадрлар үзгәрүенә бәйле рәвештә һәм Алексеевск муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турындагы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Алексеевск муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында " 2018 елның 5 июлендәге 72 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 5 пункты нигезендә»

**карар бирәм:**

1. Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе составына (Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 2018 елның 5 июлендәге 72 номерлы карарына 1 нче кушымта) түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

– “Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы Т. Н. Сергеева, комиссия секретаре” сүзләрен “Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы Л. В. Михайлова , комиссия секретаре “сүзләренә алмаштырырга;

- «Карасев С. Н. – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең Чистай районара тикшерү бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча), комиссия әгъзасы» сүзләрен «Карасев С.Н. – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең Чистай районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча), комиссия әгъзасы»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга:http:/pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы башлыгы урынбасары Г. В. Беловага йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С. А. Демидов**